ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423763, Иске Богадыа вылы, Үзәк ур.,
60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОБУГАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423763, село Старые Бугады,
ул. Центральная, дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 1 11.11.2019 ел.

**Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлегенең торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Иске Богады авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Богады авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 20 ноябренә Яңа Җияш,Югары Богады,Каенлык авылларында, 21 ноябренә Иске Богады,Иске Солтангул авылларында билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

- җирләү урыннарын карап тоту һәм зират документларын рәсмиләштерү;
-авыл җирлеге торак пунктларында урам электр лампаларын алыштыру һәм ремонтлау;
-Иске Богады җирлегендә, Үзәк,Яшьләр урамында,М. Җәлил урамында, Иске Солтангол авылында Үзәк урамда, Югары Богады авылы Лесная урамында юллар формалаштыру һәм тигезләү, ком һәм гравий салу;
-авыл җирлеге урамнарын карап тоту: грейдер белән тигезләү һәм кардан чистарту;
-су челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү чыганакларын карап тоту, су алу җайланмаларын документаль рәсмиләштерү (лицензияләү), авыл җирлегенең каптаж чишмәләрен;
- җирлек халкының күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм ял итү урыннарын оештыру.

**"ӘЙЕ"** **"ЮК"**

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Иске Богады авылы, Үзәк урамы, 58 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Иске Богады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Богады авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Фаттахов.